Елнын елында балаларнын жәйге ялын оештыруга хокvмәтебез һәм Мордовия районнары житәкчелеге тарафыннан зур игътибар бирелә.
Мордовия мәгариф министрлыгынын Матбугат хезмәте тарафыннан бастырылган мәгълvмат буенча, республикабыз территориясендә хәзерге вакытта 253 мәктәп яны лагере эшли. Аларда 9727 укучы ял итә.
Ведомствода учреждениеләр рес- публиканын 16 районында һәм Саранскида эшли, дип әйтеләр. Аларнын һәркайсында балалар очен белем бирv программалары эшләнгән, алар ялны файдалы итеп vткәрергә момкинлек бирелә.
Мәктәп яны лагерьлары программа-лары балаларнын яшь vзенчәлекләрен исәпкә алып тозелгән. Ул vз эченә акцияләр һәм рухи-әхлакый, патриотик тәрбия бирv, сәламәт яшәv рәвешен пропагандалауга юнәлтелгән торле кызык лы ярышларны алган. Дәvләт ярдәменә мохтаж балаларга аеруча игътибар ителә.

Мәсәлән, июньнен бер конендә генә дә Ләмберә районы татар мәктәпләрендә оештырылган ял лагерьлары тыгыз эш-чәнлек алып баралар.

Пензятка авылы китапханәсе белән авыл Мәдәният йорты хезмәткәрләре, «Салават кvпере» мәктәп яны лагерендә ял итvче балалар очен, экологик уен оештырганнар.
Шулай ук лагерьларда ял итvчеләр очен Аксен, Кривозерье Мәдәният йортлары хезмәткәрләре кvнел ачу программалары vткәргәннәр.
Рузаевка районы Татар Пешлә мәдә- ният йорты хезмәткәрләре vткән атнада мәктәп яны лагерендә ял итvчеләр очен конкурслар, викториналар, уенлы программалары дискотека белән тәмамланган.
Шул ук числода Кадошкино районы Латышовка мәктәбе «Кояш нуркайлары» дигән ял лагерендагы балалар авыл китапханәсендә «Китап коне» vткәргәннәр.
Кондезге мәктәп яны лагерьлары vз эшчәнлекләрен хәрби-патриотик, туган якны ойрәнv, лингвистик, сәнгати-эстетик, физкультура-спорт юнәлешләрендә алып баралар.
Үткәрелгән һәрбер чара балаларга рәхәтлек алып килгән – кvнелле ял иткәннәр.
Шулай ук июль-август айларында мәк- тәпләрдә ял мәйданчыклары оештыру планлаштырыла.

Н.ХӘЛИЛ